**Татарстан Республикасы**
**Нурлат муниципаль районы**
**Төрнәс авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

№ 74 02 июль 2024 ел

Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты нигезендә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Төрнәс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1) физик затның үлеменнән соң өч еллык срокның тәмамлануы яки аны гражданлык процессуаль законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә үлгән дип игълан итү, әгәр варислар закон буенча да, васыять буенча да булмаса, яки варисларның берсе дә мирас алырга хокуклы булмаса яки барлык варислар мирастан баш тартса һәм шул ук вакытта аларның берсе дә башка варис файдасына баш тартуын күрсәтмәгән булса;

2) салым түләүченең – физик затның гражданнарга стационар социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмада булуы;

3) салым салу объекты булган милеккә милек хокукы туктатылган көннән өч еллык срокның тәмамлануы;

4) җирле салымнарны һәм җыемнарны түләү буенча бурыч барлыкка килгән көннән алып өч еллык срокның тәмамлануы.

5) варислар мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яки мирас ачылганнан соң бер ел эчендә кабул ителмәгән очракта үлгән яки һәлак булган дип игълан ителгән физик затларда бурычлар булу;

6) 2024 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдән чыгарылган җирле салымнар буенча оешмаларга яки шәхси эшмәкәрләргә исәпләнгән бурычлар булу;

7) физик затларда Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң 500 сумнан артмаган суммада бурыч булу;

2. Төбәк салымнары суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре булуын раслаучы документлар булып:

1) карарның 1 пунктының 5 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

а) физик затның яшәү урыны буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе;

б) физик затның үлеме сәбәпле салым органнары исәбеннән төшерелүе турында мәгълүмат;

в) мирас хокукы турында таныклык бирү турында мәгълүмат булмау турында салым органы белешмәсе;

2) әлеге карарның 1 пунктының 6 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

а) оешма, шәхси эшмәкәр, шәхси эшмәкәр статусын югалткан физик зат исәпкә алынган урын буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе:

б) салым гамәлдән чыгарылган норматив хокукый акт (исеме, датасы, номеры) турында мәгълүмат;

3) әлеге карарның 1 пунктының 7 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

а) салым органының 500 сумнан артмаган бурычлар булуы турында белешмәсе.

3. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге Советының «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2023 елның 2 маендагы 52 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Төрнәс авыл җирлеге
Советы Рәисе С.В.Белов